
Укытучылар коненә һәм Олкәннәр айлыгына багышланган чаралар кысаларында рубриканы дәвам итә-без. Интернет челтәрдә хормәтле укытучыларыбызнын янадан-яна исем-нәре ишетелә.
Шулай, “Юлдаш” газетасы битләрендә мәкаләләре, vзенен уй-фикерләре белән еш басылып килгән Айса Ахмяров ВКонтакте битләрендә дә еш кvренә. Менә анын укытучыларга олы хормәте, укытучыларнын тырыш хезмәтенә зур бәя биреп рәхмәтләрен белдерve: “Хормәтле Монирә Исмәгыйль кызы!
Озак еллар намуслы хезмәтегез очен рәхмәт сезгә! Сугыштан сонгы авыр елларда туган авылым Ромоданово районы Белозерьеда эшләгәнегез очен рәхмәт сезгә! Рәхмәт сезгә! Ин изге теләкләр!      Укытучылар, Сез безнен йорәгебездә мәнгегә каласыз!!!”
Бу сvзләрне сезнен игътибарыгызга Кадошкино районы администрациясе сайтында язылган. Анда укытучылар турында яна рубрика эшли. Бvген «Латыш урта гомуми белем бирv мәктәбе» укытучыларын тәкъдим итәләр. Очрашу Монирә Исмәгыйль кызы Донская белән диелгән. Биографик белешмә белән рубриканы башлап жибәрәләр – танышабыз.
Монирә Исмәгыйль кызы Донская Кадошкино районы Латышовка жидееллык мәктәбен тәмамлап, Ләмберә педагогия техникумына укырга керә. Аны тәмамлаганнан сон, элек Белозерье авылы Ләмберә районына кергән, шунда педагогик хезмәткә юллыйлар. Ә 1950 елдан Латышовка мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып хезмәт биографиясен дәвам итә. Аннары озайтылган кон торкеме тәрбиячесе булып та эшли. Монирә Исмәгыйль кызы Донскаянын эш стажы 40 ел. Ул берничә буын укучыны укырга, язарга, эшләргә, яхшы кешеләр булырга ойрәткән педагог. Тырыш хезмәте грамоталар белән бvләкләнгән, бик кvп Рәхмәт хатлары бар. Шулай ук Монирә Исмәгыйль кызы Донская Хезмәт ветераны һәм тыл ветераны.
Укытучылар елында һәрвакыт хәтер-ләрендә йорткән хормәтле беренче укытучыларын, Монирә Исмәгыйль кызын ихластан котлап ныклы сәламәтлек, иминлек һәм озын гомер телиләр.

**Наилә НАСЫРОВА**